ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

29 декабря 2017г.

№ 8202

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
халыкны янгын куркынычсызлыгы
чараларына өйрәтүне оештыру һәм
үткәрү тәртибе турында

Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге Федераль законның 16 маддәсе, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү» янгын куркынычсызлыгы нормаларын раслау турында» 2007 елның 12 декабрендәге 645 нче боерыгы, шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Теркәлгән Яр Чаллы шәһәре территориясендә халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру һәм үткәрү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.А. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 29 декабрендәге
8202 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру һәм үткәрү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре территориясендә халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру һәм үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) Яр Чаллы шәһәре территориясендә халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыруга карата бердәм таләпләрне билгели, аның төп максатларын һәм бурычларын, шулай ук халык төркемнәрен, янгын куркынычсызлыгы чараларына, янгынның куркыныч факторларыннан саклану ысулларына һәм янгын шартларында үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтүнең периодик рәвештә кабатлануын һәм формаларын билгели.

2. Тәртип «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 нчы карары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Оешмалар хезмәткәрләрен янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү» янгын куркынычсызлыгы нормаларын раслау турында» 2007 елның 12 декабрендәге 645 нче боерыгы нигезендә эшләнде.

3. Янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү, янгынга каршы пропаганданы һәм янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә инструктажны гамәлгә ашыру даими күп дәрәҗәле характерга ия һәм торак фондында, оештыру-хокукый формаларына һәм милекчелек формаларына бәйсез рәвештә оешмаларда, шулай ук хезмәт эшчәнлеге процессында белемнәрне камилләштергәндә үткәрелә.

4. Яр Чаллы шәһәре территориясендә халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүнең төп максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) эшчәнлекнең төрле өлкәләрендә гражданнар тарафыннан янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү;

2) янгын чыккан очракта гражданнар тарафыннан эшләр тәртибен, янгынның куркыныч факторларыннан саклану ысулларын, беренчел янгын сүндерү чараларын куллану һәм янгында зыян күрүчеләргә беренче медицина ярдәме күрсәтү кагыйдәләрен өйрәнү;

3) янгыннар санын һәм аларның тискәре нәтиҗәләренең авырлык дәрәҗәсен киметү;

4) Яр Чаллы шәһәре территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм халыкның үзара эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күтәрү;

5) халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү процессының максатчан, планлы һәм өзлексез булуын тәэмин итү;

6) янгынга каршы пропаганда формаларын һәм методларын камилләштерү.

5. Янгын куркынычсызлыгы чараларын өйрәнүне түбәндәгеләр үтәләр:

1) хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы гражданнар (алга таба – эшләүче халык);

2) хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаучы гражданнар (алга таба – эшләмәүче халык);

3) мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендәге балалар һәм белем бирү учреждениеләрендә укучы затлар (алга таба – укучылар).

6. Янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү түбәндәге формаларда үткәрелә:

1) махсус янгынга каршы инструктаж программалары буенча дәресләр;

2) лекцияләр, әңгәмәләр, өйрәтүче фильмнар, мөстәкыйль әзерлек;

3) укулар һәм тренировкалар.

7. Эшләүче халыкны өйрәтү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) эш урыны буенча янгынга каршы инструктаж һәм дәресләр үткәрү, әзерлек, белем арттыру һәм квалификация күтәрү формаларында оешма эшчеләре, җитәкчеләре һәм белгечләренең белем дәрәҗәләрен күтәрү;

2) инструктаж үткәрүче һәм инструктаж үтүченең имзасын, шулай ук инструктаж үткәрү датасын кую мәҗбүри булган инструктаж журналында теркәлеп, яшәү урыны буенча кимендә елга бер тапкыр янгынга каршы инструктаж үткәрү;

3) янгынга каршы темаларга лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү, өйрәтүче фильмнар карау;

4) оешмаларда һәм яшәү урыны буенча укуларга һәм тренировкаларга җәлеп итү;

5) мөстәкыйль рәвештә янгын куркынычсызлыгы таләпләрен һәм янгын чыкканда эш итү тәртибен өйрәнү.

8. Эшләүче халыкны өйрәтүне һәм белемнәрен тикшерүне үткәрү өчен оешмаларда янгын-техник комиссияләр төзелергә, шулай ук билгеләнгән тәртиптә халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү буенча хезмәт күрсәтүче оешмалар җәлеп ителергә мөмкин.

9. Дәресләр укыту буенча заманча техник чаралар һәм күрсәтмә әсбаплар (плакатлар, табигый экспонатлар, макетлар, модельләр, кинофильмнар, видеофильмнар, диафильмнар һ.б.) кулланып, махсус җиһазландырылган кабинетларда (биналарда) үткәрелә.

10. Эшләмәүче халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү яшәү урыны буенча идарә компанияләрендәге укыту-консультация пунктларында үткәрелә һәм түбәндәгеләрне күздә тота:

1) янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат бирү, шул исәптән җыелышлар оештыру һәм үткәрү юлы белән;

2) яшәү урыны буенча кимендә елга бер тапкыр янгынга каршы инструктаж үткәрү;

3) янгынга каршы темаларга лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү;

4) яшәү урыны буенча укуларга һәм тренировкаларга җәлеп итү;

5) мөстәкыйль рәвештә янгын куркынычсызлыгы мәсьәләләре буенча кулланмалар, белешмәлекләр, листовкалар һәм буклетларны өйрәнү, радиотапшырулар тыңлау һәм телепрограммалар карау.

11. Белем бирү оешмаларында Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге хезмәткәрләре көче белән укучыларны янгын куркынычсызлыгы чараларына мәҗбүри өйрәтү үткәрелә.

Өйрәтү түбәндәгеләрне күздә тота:

1) белем бирү учреждениесенең төрен һәм тибын исәпкә алып, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы белән килешенгән гомуми һәм һөнәри белем бирү программалары кысаларында дәресләр үткәрү;

2) янгынга каршы темаларга лекцияләр, әңгәмәләр үткәрү, өйрәтүче фильмнар карау;

3) тематик кичәләр, конкурслар, викториналар һәм дәрестән тыш вакытта үткәрелә торган башка чаралар;

4) белем бирү учреждениеләренең тулай торакларында яшәүчеләргә кимендә елга бер тапкыр янгынга каршы инструктаж үткәрү;

5) шартлау һәм янгын куркынычы тудыручы матдәләр һәм материаллар белән эш итүгә бәйле эшләр (дәресләр) башлану, янгын куркынычсызлыгы таләпләре билгеләнгән культура-массакүләм һәм башка чаралар үткәрү алдыннан янгынга каршы инструктаж үткәрү;

6) белем бирү учреждениеләре, тулай торак биналарыннан эвакуацияләү буенча укулар һәм тренировкаларда катнашу.

12. Эшләүче халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү янгынга каршы инструктаж һәм (яки) янгын-техник минимумы программалары буенча үткәрелә.

Эшләүче халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү тәртибе, төрләре, сроклары, шулай ук һөнәри белем бирү программалары эчтәлегенә карата таләпләр, аларны раслау һәм килешенү тәртибе янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

Тормышка ашырыла торган программа төренә карап, эшләүче халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтү турыдан-туры эш урынында һәм (яки) белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда үткәрелә.

13. Янгынга каршы пропаганда массакүләм мәгълүмат чаралары аша, махсус әдәбият һәм реклама продукциясе бастыру һәм тарату, тематик күргәзмәләр, смотрлар, конференцияләр ярдәмендә һәм халыкка мәгълүмат бирүнең Россия Федерациясе законнары белән тыелмаган башка формаларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла. Янгынга каршы пропаганданы дәүләт хакимияте органнары, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар үткәрә.

14. Гражданнарны янгынга каршы инструктаж формасында өйрәтү билгеләнгән тәртиптә расланган янгын куркынычсызлыгы буенча норматив документлар таләпләре, шулай ук янгын чыкканда үз-үзеңне тоту һәм беренчел янгын сүндерү чараларын куллану кагыйдәләре белән таныштыру максатында аларның эш (уку), даими яки вакытлыча яшәү урыны буенча үткәрелә.

15. Шартлау-янгын куркынычы тудыручы матдәләр һәм материаллар житештерү, саклау, алар белән эш итү, транспортлау белән бәйле хезмәт һәм уку эшчәнлегенең барлык төрләре вакытында гражданнарга янгынга каршы инструктаж эшләр (дәресләр) башланыр алдыннан хезмәтне саклау һәм куркынычсызлык техникасы буенча инструктаж белән бер үк вакытта үткәрелә.

16. Гражданнарга янгынга каршы инструктаж оештыру алар торак, гараж, дача һәм башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативларына, бакчачылык берләшмәләренә, торак милекчеләре ширкәтләренә кергәндә, шулай ук социаль наем, махсуслаштырылган торак урынын наемга алу килешүләре буенча гражданнарга торак бина биргәндә үткәрелә һәм әлеге оешмаларның вәкаләтле вәкилләренә йөкләнә.

17. Кешеләр күпләп (50 һәм аннан күбрәк кеше) җыела торган объектлар персоналына кешеләрне куркынычсыз һәм тиз эвакуацияләү буенча тренировкалар кимендә алты айга бер тапкыр үткәрелә.

18. Эшләүче халыкны янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә өйрәтүне оештыруга һәм аның үз вакытында башкарылуына һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре буенча аларның белемнәрен тикшерүгә эш бирүче оешмаларның администрацияләре (милекчеләре) һәм вазыйфаи затлары, юридик зат булып оешмаган эшмәкәрләр, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эш бирүче белән хезмәт килешүе төзегән хезмәткәрләр җаваплы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Г.К. Әхмәтова